КИЛЕШЕНГӘН
Яр Чаллы шәһәренең
МБУ «Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» директор урынбасары
_____________ Г.Д. Юстус
«_9_» _января_ 2024 ел

РАСЛЫЙ
Яр Чаллы шәһәренең
МБУ«Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» директоры
_____________ В.М. Гайнуллина
«_9_» _января_ 2024 ел

**«Әйдәгез, дуслашыйк!» әдәби бәйгесе**
**НИГЕЗЛӘМӘСЕ**

**1. Гомуми нигезләмә**

1.1. Нигезләмә «Әйдәгез, дуслашыйк!» әдәби бәйгесенең (алга таба – Бәйге) максатларын һәм бурычларын, шартларын һәм үткәрү тәртибен билгели.
1.2. Бәйге язучы Факил Сафин иҗаты белән кызыксынган, шигърият сөючеләр арасында үткәрелә.
1.3. Бәйгенең оештыручысы – «Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесе (алга таба –«ҮКС» МБУ).

**2. Бәйгенең максатлары һәм бурычлары**

2.1. Бәйге балаларда нәфис сүз белән кызыксыну, шигъри сүзнең матурлыгын һәм аһәңен тоя белүне тәрбияләү максатыннан үткәрелә.
2.2. Бәйгенең бурычлары:

- Факил Сафин иҗатын популярлаштыру;
- Чаллы язучылары иҗатына кызыксыну арттыру;
- Балаларның әдәби иҗатка булган сәләтләрен үстерү һәм таныту;
- балаларда шигъри әсәрләргә карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү.

**3. Бәйгедә катнашучылар**

3.1. Бәйгедә яше 3яшьтән 14 яшькәчә кадәр (кертеп) булган балалар катнаша ала.
3.2. Бәйге түбәндәге яшь төркемнәренә бүленә:

- 3 яшьтән 5 яшькә кадәр
- 6 яшьтән 7 яшькә кадәр
- 8 яшьтән 10 яшькә кадәр
- 11 яшьтән 14 яшькә кадәр.

**4. Бәйгенең шартлары**

4.1. Бәйгегә шагыйрь-юбиляр Факил Сафин шигырьләрен татар телендә яттан укуның видеоязмалары кабул ителә.
4.2. Бәйге эшләре түбәндәге номинацияләрдә бәяләнә:

- «Татарстан – туган ягым!»
- «Табигать кочагында»
- «Әткәй, әнкәй, туган нигезем»

4.3. Бәйгедә катнашу бәясе 200 сум. Взнос теләсә кайсы банк бүлекчәләрендә «ҮКС» МБУ тарафыннан күрсәтелә торган «Түләүле хезмәтләргә тарифлар исемлеге»нә ярашлы түләнә (Кушымта №1). Инвалидларга һәм мобилизацияләнгән гражданнарның балаларына Бәйгедә катнашу бушлай (белешмә күчермәсе кирәк).
4.4. Бәйгедә катнашу өчен теркәлү карточкасы (Кушымта №2), оештыру взносын түләү турында квитанция күчермәсе, видеороликлар бердәм пакет белән оештыручының электрон почтасы адресына җибәрелә: cbs_filial12@mail.ru . Түләү квитанциясез бәйгегә эшләр кабул ителми.
4.5. Бәйгедә катнашу катнашучының Бәйге шартлары һәм шәхси мәгълүматларны эшкәртү белән килешүен аңлата.

### 5. Бәйге эшләренә таләпләр

5.1. Видео 3 минуттан да артык булмаган MP4 форматында башкарыла. Роликны яздырганда катнашучыга үз фамилиясен һәм исемен, әсәрнең исемен һәм авторын әйтергә кирәк.

5.2. Нигезләмәгә туры килмәгән Бәйге эшләре кабул ителми һәм каралмый.

### 6. Эшләрне бәяләү критерийлары

6.1. Бәйге эшләрен бәяләү 5 баллы система буенча үткәрелә. Ахыргы нәтиҗәгә баллар кушылу юлы белән ирешелә.

6.2. Бәйге эшләре түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә:

- әсәрне башкаручының яшь үзенчәлекләренә туры китереп сайлау;
- башкару осталыгы;
- әсәрне яттан белү;
- сөйләмнең аңлаешлылыгы һәм дөреслеге;
- сирәк башкарыла торган әсәрне сайлау.

6.3. Чыгыш вакытында декорацияләр, костюмнар һәм музыка кулланылырга мөмкин.

### 7. Бәйгене үткәрү вакыты

7.1. Бәйге 3 этапта үткәрелә:

- 1 этап: 2024 елның 9 гыйнвареннән 10 мартына кадәр – бәйге эшләрен кабул итү;
- 2 этап: 2024 елның 11 мартыннан 14 мартына кадәр – бәйгегә йомгак ясау;
- 3 этап: 2024 елның 15 мартыннан 20 мартына кадәр – электрон дипломнар һәм сертификатлар җибәрү.

7.2. Кабул итү вакыты тәмамланганнан соң, өчтән азрак эш тапшырылган очракта, Бәйге уздырылмаган дип таныла.

### 8. Йомгак ясау һәм бүләкләү

8.1. Эшләрне Бәйге жюрие бәяли.

8.2. Жюри Бәйгедә җиңүчеләрне балларны кушу ысулы белән билгели. Жюри карары протокол белән рәсмиләштерелә һәм яңадан каралмый.

8.3. Бәйге җиңүчеләренә һәр яшь төркемендә һәр номинациядә I, II, III урыннар өчен дипломнар тапшырыла. Урын алмаган катнашучыларга сертификат тапшырыла. Дипломнар һәм сертификатлар электрон рәвештә катнашучының теркәлү карточкасында күрсәтелгән электрон почта адресына җибәрелә.

### 9. Бәйгенең рекламасы

Бәйгене үткәрү һәм аның нәтиҗәләре китапханә сайтында яктыртыла: *библиотека-челны.рф* һәм ВКонтакте социаль челтәрендә *12нче китапханә (Яр Чаллы)* битендә https://vk.com/club137987058

Бәйгене үткәрү урыны: Яр Чаллы китапханәләр системасының 12нче филиалы, Яр Чаллы шәһәре, Ш. Усманов ур., 48 (14/01)

e-mail: cbs_filial12@mail.ru

Белешмәләр өчен телефон: 35-33-86

Җаваплы: Аксуева Әлфия Зөфәр кызы

**Кушымта №1**

**Түләү өчен реквизитлар**

| | |
|---|---|
| МБУ «Централизованная библиотечная система» | |
| ИНН/КПП | 1650105517/165001001 |
| Расч. счет | 03234643927300001100 |
| Корр. счет | 40102810445370000079 |
| БИК | 019205400 |
| Банк | Отделение - НБ Республика Татарстан Банка России//УФК по Республике Татарстан г. Казань |
| Лицевой счет | ЛБВ 30800866-ЦБС |
| ОКТМО | 92730000 |
| КБК | 00000000000000000131 |
| Назначение платежа | Библиотека-филиал №12, Ф.И. участника, конкурс «Әйдәгез, дуслашыйк!» |

**Кушымта №2**

**Теркәлү карточкасы**

Катнашучының фамилиясе, исеме...............................................................................................
Катнашучының яше.......................................................................................................................
Белем бирү учреждениесе.............................................................................................................
..........................................................................................................................................................
Җитәкчесе.......................................................................................................................................
Телефон.............................................................E-mail..................................................................

Дата: ___________2024 ел.